КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1141

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 14 февраль, 64 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 14 февраль, 64 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 28 июнь, 373 нче; 2006 ел, 30 декабрь, 693 нче; 2023 ел, 24 март, 347 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның уналтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең республика һәм җирле органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгына, сорала торган акча күләменең нигезләве теркәлгән документларны (смета-финанс исәп-хисапларын кертеп), шулай ук, кирәк булган очракта, Татарстан Республикасының кызыксынучы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм бүтән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары бәяләмәләрен кертә.»;

өченче абзацта татар текстында «Эш итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы бирелә торган органнар» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, шулай ук бюджетларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин